2024 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Миңлебай авылы җирлеге Миңлебай станциясе гражданнарның үзара салымын кертү турында

ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

3 декабрь 2023 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Миңлебай авыл җирлегенең Миңлебай станциясе гражданнар җыены карар кабул итте:

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Миңлебай авыл җирлегенең Миңлебай станциясе территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 700 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә: Минлебай авыл җирлеге Миңлебай станциясе торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү һәм ремонтлау (асфальтлаштыру), техник күзәтү үткәрү.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Миңлебай станциясе, Шоссе урамы, 20а йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Миңлебай авыл җирлеге башлыгы И.М. Рәхимов